МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.09.2022 Казан ш. 879

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 25 апрелендәге 263 номерлы боерыгы белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 25 апрелендәге 263 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13.07.2020 №503, 02.10.2020 №692, 09.06.2021 №410, 06.08.2021 №567, 23.11.2021 №862 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 21 сентябрендә № 879боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 25 апрелендәге 263 номерлы боерыгы елән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.3.1 – 1.5 пунктларны көчен югалткан дип танырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү (алга таба – айлык акчалата түләү) билгеләү һәм аны түләп бару.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсе йөзендә «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк).

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар (әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталындагы (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба далее - Единый портал) шәхси кабинетына.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр телефонга смс-хәбәр итеп җибәрелергә мөмкин.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән барлык кирәкле документлар белән гариза теркәлгән көннән алып, 10 эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү чоры арттырыла:

гариза Бердәм порталдан файдаланып яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән мөрәҗәгать иткәндә бирелгән очракта документлар җыелмасы тулы күләмдә тапшырылмаса – 10 эш көненә;

ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратыла торган мәгълүматлар килмәгән очракта, – 20 эш көненә.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризада һәм (яки) документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булу факты билгеләнгән очракта, айлык акчалата түләү билгеләү яки билгеләүдән баш тарту турындагы карарны кабул итү срогы биш эш көненә туктатыла.

2.4.4. Мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында хәбәр юлланган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә

(гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

**2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге**

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «3 яшьтән 7 яшькәчә балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү тәртибенә карата төп таләпләр, әлеге айлык түләүне билгеләү өчен кирәкле документларның (белешмәләрнең) якынча исемлеген һәм аны билгеләү турындагы гаризаның типлаштырылган формасын раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 384 номерлы карары белән расланган форма буенча айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза, банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла);

2) бала туу турында документның күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган тәрҗемәсе – туу тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очракта;

3) гаилә әгъзасының үлүе турындагы документ күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган тәрҗемәсе – вафатлык тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очракта;

4) өйләнешү (аерылышу) турында документның күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган тәрҗемәсе – өйләнешү (аерылышу) тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очракта;

5) мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзалары милегендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган бер фатирда гражданнарның бергә яшәве мөмкин булмаган хроник чирләрнең катлаулы формалары исемлегендә каралган хроник чирнең катлаулы формасыннан интегә торган мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гаилә әгъзасы биләп торган торак урын (аның бер өлеше), шулай ук билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын (аның бер өлеше) булуы турында документ күчермәсе;

6) 23 яшьтән кечерәк мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яки югары уку йортында көндезге уку формасы буенча белем алу факты турында документ күчермәсе;

7) 23 яшьтән кечерәк мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яки югары уку йортында көндезге уку формасы буенча белем алган очракта стипендияне алып бетермәү факты турындагы документ күчермәсе;

8) мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан өч айдан артык өзлексез рәвештә дәвалану факты, шуның нәтиҗәсендә вакытлыча хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыра алмаулары турында документ күчермәсе;

9) мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының тулы дәүләт тәэминатында булуы турында ңокумент күчермәсе;

10) мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзаларының чакырылу буенча хәрби хезмәт үтүе турында, шулай ук хәрби һөнәри оешмада һәм югары белем бирүче хәрби уку йортында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән затның хәрби хезмәткәр статусы турында документ күчермәсе;

11) мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының суд карары буенча мәҗбүри дәвалауда булуы турында документ күчермәсе;

12) һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче уку йортларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы затларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучы фән-педагогика кадрларына түләнә торган стипендияләр, Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалата түләүләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация күләме хакында документ күчермәсе;

13) отставкага чыккан судьяларга гомер буе айлык акчалата түләү күләме турында документ күчермәсе;

14) хәрби хезмәттән, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендәге хезмәттән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнардагы хезмәттән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында документ күчермәсе;

15) хәрби хезмәт, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнарда хезмәт итүче (хезмәт иткә) затлар ала торган пенсия күләме турында документ күчермәсе;

16) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү турында» 2021 елның 22 октябрендәге 995 номерлы карары белән расланган Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне бирү тәртибе һәм шартларының (алга таба – Тәртип һәм шартлар) 30 пунктының «а» һәм «е» пунктчаларында каралган керемнәрнең күләме турында документ күчермәсе (әгәр мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары

Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, федераль куркынычсызлык хезмәте органнары, дәүләт сагы органнары, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләре булса (булып торган булсалар));

17) дәүләт бурычларын яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган, алынган компенсация күләме турында документ күчермәсе;

18) мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан Россия Федерациясеннән читтә алынган керемнәр күләме турында документ күчермәсе;

19) эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр күләме турында документ күчермәсе;

20) «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр күләме турында документ күчермәсе;

21) авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр күләме турында документ күчермәсе;

22) мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары милегендә Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә күпбалалы дип танылган гаиләгә (алга таба – күпбалалы гаилә) дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү кысаларында Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органнары тарафыннан бирелгән яисә аларны сатып алу бәясе «Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм Россия Федерациясенең Арктика зонасында һәм Россия Федерациясенең башка Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгыш территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон нигезендә күчемсез мөлкәт сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү кысаларында бирелгән акчалар хисабыннан тулы күләмендә түләнгән, «торак», «торак төзелмә», «торак йорт» билгеләнешендәге биналар, «торак» билгеләнеше булган урыннар, җир кишәрлекләре булуы турында документ күчермәсе;

23) мөрәҗәгать итүчегә яки аның гаилә әгъзаларына теркәлгән дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелә торган яисә аны сатып алу бәясе күчемсез мөлкәтне сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән акчалар исәбеннән тулысынча түләнгән автотранспорт (мототранспорт) чарасының булу-булмавы турындагы документ күчермәсе;

24) автотранспорт (мототранспорт) чарасының, кече үлчәмле судноның, үзйөрешле машинаның яки башка төр техниканың арест астында булуы һәм (яки) эзләнүдә булуы турында;

25) алынган грантлар, субсидияләр һәм эшкуарлыкка ярдәм итү кысаларында бирелә торган максатчан чыгымнарга ия булган башка керемнәр турында;

26) хатын-кызның йөклелеге турында. Мөрәҗәгать итүче хатын-кызның йөклелеге турындагы документларны (белешмәләрне) Тәртип һәм шартларның 17 һәм 18 пунктларында билгеләнгән срокларда Тәртип һәм шартларның 31 пункты нигезендә гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорга һәм (яисә) гариза биргән көнгә тапшырырга хокуклы;

27) айлык акчалата түләү билгеләү өчен гариза түләү алучы вәкаләт биргән зат яки түләү алучының законлы вәкилләре тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә бирелгән очракта, ышаныч кәгазенең күчермәсе.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче гаилә әгъзаларының үзләренең персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы булуын һәм мөрәҗәгать итүченең органга яки оешмага персональ белешмәләрне тапшырганда алар исеменнән эш итү вәкаләтен раслый торган документны (документларны) (ирекле формада) тапшыра.

2.6.3. Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны күрсәтә.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

2.6.5. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмалардан – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә дә алына.

2.6.6. Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк, КФҮ) белгече тарафыннан таныклана.

2.6.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Бердәм порталда урнаштырылган.

2.6.8. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

Үзәк бүлекчәсенә яисә почта аша кәгазьдә;

күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша;

Бердәм портал аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре (алга таба – «Интернет» челтәре) аша;

2.6.9. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.6.10. Гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гаризаны һәм кирәкле документларны «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә Идентификация һәм аутентификациянең бердәм (алга таба – ИАБС) системасында теркәлү

(аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6.11. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

бала тууы турында, баланың тууы тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

баланың вафат булуы турында, баланың вафат булуы тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

гаилә әгъзасының вафат булуы турында, гаилә әгъзасының вафат булуы тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

өйләнешү (аерылышу) турында, өйләнешү (аерылышу) тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

баланы опека билгеләнүе турында;

баланың ата-аналары турында;

үзләренә карата гариза бирелгән баланың (балаларның) опекуны турында;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукларындагы чикләүләрне гамәлдән чыгару турында, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы йолып алу турында;

ата-ананың яки баланың башка законлы вәкиленең хокукка сәләте чикләнгән булуы яисә хокукка сәләтсез дип танылуы турында;

хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү (шул исәптән тотып калынган салым түләүләре) турында;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Илкүләм гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре керемнәре турында;

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында;

Россия Федерациясенең мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында законнарында каралган очракларда вафат булган иминиятләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр турында;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача керемен исәпләү чорында эшкә сәләтсез затларны карау турында;

гариза бирү вакытына һәм (яки) гаиләнең җан башына исәпләгәндә кереме исәпләнгән чорда эшсез яки эш эзләүче статусы булуы турында;

кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында, шулай ук оешма

милке белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә;

кредит оешмаларында кертемнәр буенча алынган процентлар турында;

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында;

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында;

Россия Федерациясе Салым кодексының 217.1 статьясында күрсәтелгән сроктан азрак вакыт эчендә милектә булган күчемсез милекне сатудан, шулай ук мөлкәтне арендага (наемга, поднаемга) бирүдән алынган керемнәр турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы күчемсез мөлкәт турында (шул исәптән арест астында булган);

Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлүе турында;

Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен таныклый торган, Россия Федерациясе гражданинына элек бирелгән паспортлар турында;

алына торган алиментлар турында (әгәр акчалар түләттерүчегә суд приставлары бүлегенә алиментлар түләттерүгә бәйле эш буенча вакытлыча идарәлеккә күчә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан күчерелгән булса);

автотранспорт яки мототранспорт чаралары турында;

чыгару елы биш елдан артмаган кече үлчәмле суднолар турында;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача кереме исәпләнә торган чорга мөрәҗәгать итүчене яки аның гаилә әгъзаларын иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында;

мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм ителү урыннарында булуы турында;

инвалидлык һәм аның төркеме турында (булган очракта);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләре нигезендә теркәлгән үзйөрешле машиналар һәм башка төр техника турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

мөрәҗәгать итүчегә яки аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чарасын куллану турында;

йөклелек белән бәйле рәвештә медицина оешмасында исәпкә кую, шулай ук бала тудыру яисә йөклелекне өзү турында;

лотереяны оештыручылар, тотализаторлар тарафыннан һәм хәтәрлеккә нигезләнгән башка уеннардан түләнә торган, отыш нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында;

хезмәт эшчәнлеге турында.

2.6.12. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар

мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.11 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.13. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) Үзәк бүлекчәсенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру;

2) күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү;

3) мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр:

Бердәм порталдан файдаланып яки шәхси мөрәҗәгать иткәндә гариза биргәндә тулы булмаган документлар комплекты бирү;

ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында сорала торган мәгълүматлар булмау;

мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризада һәм (яки) документларда дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булу факты билгеләнгән очракта.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

а) үзенә карата гариза тапшырыла торган баланың вафат булуын дәүләт теркәвенә алу;

б) гаиләнең җан башына уртача кереме күләменең айлык түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать итү датасына Татарстан Республикасында билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән артык булуы;

в) гаризада дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар булуы;

г) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының милегендә түбәндәгеләрнең булуы:

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының уртак милегендә булганнарын да кертеп, «торак» билгеләнешендәге, суммар мәйданы бер кешегә һәм

гаилә әгъзалары санына тапкырчыгышын исәпләгәндә 24 квадрат метрдан артып китә торган ике һәм аннан күбрәк бина (мондый бина күпбалалы гаиләгә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү кысаларында бирелгән яисә сатып алу бәясе тулы күләмендә күчемсез мөлкәт сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән очрактан тыш, шулай ук мондый бинага карата гомуми өлешле милек хокукындагы өлешләрдән тыш, аларның җыелма күләме гаиләнең барлык әгъзалары өчен гомуми мәйданының өчтән бер өлешеннән артмаса, мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гражданнарның бер фатирда яшәве мөмкин булмаган, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган авыр хроник чирләр исемлегендә каралган авыр формалы хроник чирдән интегә торган гаилә әгъзасы били торган шундый бинадан (аның бер өлешеннән) тыш, билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган шундый бинадан (аның бер өлешеннән) тыш һәм арест астында булган шундый бинадан (аның бер өлешеннән) тыш);

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының уртак өлешле милегендә булганын да кертеп, «торак», «торак төзелеш» һәм «торак йорт» билгеләнешендәге, суммар мәйданнары бер кешегә һәм гаилә әгъзалары санына исәпләгәндә тапкырчыгышы 40 квадрат метрдан артык булган ике һәм аннан күбрәк бина (мондый бина күпбалалы гаиләгә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү кысаларында бирелгән яисә сатып алу бәясе тулы күләмендә күчемсез мөлкәт сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән очрактан тыш, шулай ук мондый бинага карата уртак өлешле милек хокукындагы өлешләрдән тыш, әгәр аларның җыелма күләме барлык гаилә әгъзалары өчен аның гомуми мәйданының өчтән бер өлешеннән артмаса, һәм арест астында булган шундый бинадан тыш);

«бакча йорты» билгеләнеше белән ике һәм аннан күбрәк бина;

«торак булмаган» билгеләнеше булган ике һәм аннан күбрәк бина, «торак булмаган» билгеләнешле бүлмәләр, корылмалар (индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә, бакча җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмаларыннан, шулай ук күпфатирлы йортта гомуми милек булып торган күчемсез мөлкәт объектларыннан, бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциясез ширкәтенең гомуми файдалану милеге булып торган күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш);

транспорт чараларын кую (саклау), ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән ике һәм аннан күбрәк күчемсез мөлкәт (гараж, машина урыны) (шундый ике һәм аннан күбрәк күчемсез мөлкәт объекты – күпбалалы гаиләләр, составында инвалид булган гаиләләр, автотранспорт яки мототранспорт чарасы дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән яки автотранспорт яки мототранспорт чарасын сатып алу бәясе тулы күләмендә максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында күчемле мөлкәт сатып алу өчен бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән гаиләләр өчен);

җир кишәрлекләре (уртак өлешле милектә булган җир кишәрлекләреннән, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге, әйләнеше «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» федераль закон нигезендә җайга салына торган җирләрдән, күпбалалы гаиләләргә дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән яки сатып алу бәясе тулы күләмендә күчемсез мөлкәт сатып алуга максатчан дәүләт

социаль ярдәме кысаларында бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән җир кишәрлекләреннән тыш һәм «Дәүләт һәм муниципаль милектә булган һәм Россия Федерациясенең Арктика зонасында һәм Россия Федерациясенең башка, Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгыш территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш), аларның суммар мәйданы мөрәҗәгать итүченең яшәү (тору) урыны яки, яшәү (тору) урыны расланмаган очракта, хакыйкый яшәү урыны буенча билгеләнә һәм 0,25 гектардан артмаска тиеш, ә авыл җирлекләре яки җирлекара территорияләр өчен – 1 гектар;

д) мөрәҗәгать итүчегә һәм аның гаилә әгъзаларына түбәндәгеләрнең теркәлгән булуы (мөрәҗәгать итүчегә һәм аның гаилә әгъзаларына теркәлгән автотранспорт (мототранспорт) чаралары, кече үлчәмле суднолар, үзйөрешле машиналар яки башка төр техника күләмен билгеләгән очракта арест салынган һәм (яки) эзләтелә торган автотранспорт (мототранспорт) чаралары, кече үлчәмле суднолар һәм үзйөрешле машиналар яки башка төр техника исәпкә алынмый):

ике һәм аннан күбрәк автотранспорт чарасы (өч һәм аннан күбрәк автотранспорт чарасы – күпбалалы гаиләләр, составында инвалид булган гаиләләр, автотранспорт чарасы дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән яки автотранспорт чарасын сатып алу бәясе тулы күләмендә максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында күчемле мөлкәт сатып алу өчен бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән гаиләләр өчен), тагылмалар һәм ярымтагылмалардан тыш;

ике һәм аннан күбрәк мототранспорт чарасы (өч һәм аннан күбрәк мототранспорт чарасы – күпбалалы гаиләләр, составында инвалид булган гаиләләр, мототранспорт чарасы дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән яки мототранспорт чарасын сатып алу бәясе тулы күләмендә максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында күчемле мөлкәт сатып алу өчен бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән гаиләләр өчен);

двигателенең куәте 250 ат көченнән ким булмаган, чыгарылган елы биш елдан артмаган автотранспорт чарасы, дүрт һәм аннан күбрәк балалы гаилә алган (сатып алган) автотранспорт чарасыннан тыш;

чыккан елы биш елдан артмаган ике һәм аннан да күбрәк кече суднолар;

чыккан елы биш елдан артмаган ике һәм аннан күбрәк үзйөрешле машиналар һәм башка төр техника;

е) мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында айлык түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать итү датасына Россия Федерациясе буенча билгеләнгән, тулаем алганда халыкның яшәү минимумы күләмен арттырып җибәрә торган, кредит оешмаларында ачылган депозит счетларында (кертемнәрендә) калган акчага исәпләнгән процентлар рәвешендә керемнәр булуы;

ж) мөрәҗәгать итүчедә яки аның гаиләсенең эшкә яраклы әгъзаларында (18 яше тулмаган яшьтәге балалардан тыш) Айлык акчалата түләү билгеләү тәртибе һәм шартларының 31 пунктында каралган хисап чорына Тәртип һәм шартларның 30 пунктындагы «а», «б» (пенсияләр өлешендә), «в» (стипендияләр һәм медицина күрсәтмәләре буенча академик ялда булган чорда компенсацияләр өлешендә), «е», «к», «м» – «о», «р» пунктчаларында каралган керемнәрнең булмавы, әлеге чорга туры

килә торган түбәндәге (җыеп исәпләгәндә) очраклардан тыш:

мөрәҗәгать итүченең яки аның эшли торган гаилә әгъзаларының алты айдан артыграк эшсезлек статусында булуы;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзалары баланы өч яше тулганчы карап торган очракта;

23 яшьтән кечерәк мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге форма буенча укуы һәм стипендия алмавы;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзаларының 18 яшенә кадәрге инвалид-баланы яки балачактан I төркем инвалидны яисә I төркем инвалидны яисә 80 яшенә җитеп, дәвалау оешмасы бәяләмәсе белән даими рәвештә читләр тәрбиясенә мохтаҗ дип танылган өлкән кешене каравы;

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының өч айдан артык вакыт дәвамында өзлексез дәвалануы, шуның нәтиҗәсендә вакытлыча хезмәт эшчәнлеген башкара алмавы;

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының хәрби хезмәт узуы (демобилизация көненә кадәр өч айдан артмаган чорны да кертеп);

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм ителүе яки сак астында тотылуы (иреккә чыгу көненә кадәр өч айдан артмаган чорны да кертеп);

мөрәҗәгать итүченең балигълык яшенә җитмәгән баласының (балаларының) бердәнбер ата-анасы (законлы вәкиле) булып торуы (булуы);

мөрәҗәгать итүче гаиләсе күпбалалы булып торган (булып тора) (бу очрак бары тик мөрәҗәгать итүчегә яки аның гаилә әгъзаларының берсенә генә кагыла);

мөрәҗәгать итүче-хатын-кыз һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзалары йөкле булган (Тәртип һәм шартларның 31 пунктында каралган вакытка туры килә торган алты ай һәм аннан күбрәк вакыт эчендә йөклелек дәвамлылыгы шартында, яисә хатын-кызның йөклелек вакыты – 12 атна һәм аннан күбрәк булса, әлеге пунктчада күрсәтелгән нигез буенча гариза биргән көндә әлеге нигез буенча айлык акчалата түләүне билгеләү турында карар кабул ителми).

Әлеге пунктта күрсәтелгән нигезләр буенча керемнәр булмау чорлары тулаем бәяләнә. Күрсәтелгән нигезләрдә керемнәр булмаган чор Тәртип һәм шартларның 31 пунктында каралган хисап чорына җыеп исәпләгәндә исәп-хисап чорының 10 һәм аннан күбрәк аен тәшкил итсә, айлык түләү билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителми.

Тәртип һәм шартларның 30 пунктының «а» пунктчасының өченче җөмләсендә каралган шартларны исәпкә алып, айлык түләүләрне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул иткәндә әлеге пунктчада каралган нигез буенча айлык түләүне билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителми;

з) үзенә карата гариза алынган баланың сигез яшен тутыруы, Тәртип һәм шартларның 3 пунктындагы өченче абзацында каралган очрактан тыш;

и) мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә Тәртип һәм шартларның 16 пунктында күрсәтелгән документларның (белешмәләрнең) («ф» һәм «ц» пунктчаларыннан тыш), шулай ук Тәртип һәм шартларның 17 һәм 18 пунктларында күрсәтелгән чорларда документларның (белешмәләрнең) тапшырылмавы;

л) үзенә карата гариза тапшырыла торган балага карата башка законлы вәкилгә

айлык акчалата түләү билгеләнү фактының билгеләнүе;

л) мөрәҗәгать итүче тарафыннан Тәртип һәм шартларның 23 пункты нигезендә гариза һәм (яки) документлар эшләп бетерү өчен кире кайтарылганнан соң биш эш көне эчендә кирәкле гаризаның һәм (яки) документларның тапшырылмавы.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

**2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары**

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

**2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты**

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

**2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры**

2.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.11.2. Үзәкнең эш вакыты беткәч яки ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән гариза икенче эш көнендә теркәлә.

**2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр**

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла, көтү заллары (бүлмәләре) мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителә, аларда Үзәк бүлекчәсенең урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат, шулай ук, тутыру үрнәкләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларның рәвешләре урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә

туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте

күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтен күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү;

Үзәк бүлекчәсе бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

инвалидларга бина危ларның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта, Бердәм портал аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнеш таләп ителми.

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче Министрлык (http://mtsz.tatarstan.ru) сайтында, Бердәм порталда (http://www.gosuslugi.ru) алынырга мөмкин.

2.13.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.

Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза Үзәк бүлекчәсенә теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк бүлекчәсе белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Үзәк белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Бердәм порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм порталдан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә җибәрелә. ИАБС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3

пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Бердәм порталда шәхси кабинетка Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.4. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.14.5. Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсенең телефон номеры аша телефон элемтәсе аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.6. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.»;

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«айлык акчалата түләүне билгеләү (бирүдән баш тарту турында) карар әзерләү;»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, вәкаләтле органнарга түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

бала тууы турында, баланың тууы тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

баланың вафат булуы турында, баланың вафат булуы тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

гаилә әгъзасының вафат булуы турында, гаилә әгъзасының вафат булуы тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

өйләнешү (аерылышу) турында, өйләнешү (аерылышу) тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

баланы опека билгеләнүе турында;

баланың ата-аналары турында;

үзләренә карата гариза бирелгән баланың (балаларның) опекуны турында;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукларындагы чикләүләрне гамәлдән чыгару турында, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы йолып алу турында;

ата-ананың яки баланың башка законлы вәкиленең хокукка сәләте чикләнгән булуы яисә хокукка сәләтсез дип танылуы турында;

хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү (шул исәптән тотып калынган салым түләүләре) турында;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Илкүләм гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре керемнәре турында;

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында;

Россия Федерациясенең мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында законнарында каралган очракларда вафат булган иминиятләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр турында;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача керемен исәпләү чорында эшкә сәләтсез затларны карау турында;

гариза бирү вакытына һәм (яки) гаиләнең җан башына исәпләгәндә кереме исәпләнгән чорда эшсез яки эш эзләүче статусы булуы турында;

кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында, шулай ук оешма милке белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә;

кредит оешмаларында кертемнәр буенча алынган процентлар турында;

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында;

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында;

Россия Федерациясе Салым кодексының 217.1 статьясында күрсәтелгән сроктан азрак вакыт эчендә милектә булган күчемсез милекне сатудан, шулай ук мөлкәтне арендага (наемга, поднаемга) бирүдән алынган керемнәр турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы күчемсез мөлкәт турында

(шул исәптән арест астында булган);

Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлүе турында;

Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен таныклый торган, Россия Федерациясе гражданинына элек бирелгән паспортлар турында;

алына торган алиментлар турында (әгәр акчалар түләттерүчегә суд приставлары бүлегенә алиментлар түләттерүгә бәйле эш буенча вакытлыча идарәлеккә күчә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан күчерелгән булса);

автотранспорт яки мототранспорт чаралары турында;

чыгару елы биш елдан артмаган кече үлчәмле суднолар турында;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача кереме исәпләнә торган чорга мөрәҗәгать итүчене яки аның гаилә әгъзаларын ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында;

мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының ирektән мәхрүм ителү урыннарында булуы турында;

инвалидлык һәм аның төркеме турында (булган очракта);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләре нигезендә теркәлгән үзйөрешле машиналар һәм башка төр техника турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

мөрәҗәгать итүчегә яки аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чарасын куллану турында;

йөклелек белән бәйле рәвештә медицина оешмасында исәпкә кую, шулай ук бала тудыру яисә йөклелекне өзү турында;

лотереяны оештыручылар, тотализаторлар тарафыннан һәм хәтәрлеккә нигезләнгән башка уеннардан түләнә торган, отыш нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында;

хезмәт эшчәнлеге турында.»;

3.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Айлык акчалата түләүне билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү.»;

3.5.1 пунктта:

дүртенче һәм бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән) баш тарту турында) электрон рәвештә карар проекты рәсмиләштерә;

айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештәге карар проектын имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә юллый.»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Айлык акчалата түләүне билгеләү (бирүдән баш тарту турында) карар кабул итү:»;

унынчы һәм унберенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризада һәм (яки) документларда дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булу факты ачыкланган очракта, Үзәк бүлекчәсе төзәтелергә тиешле мәгълүматны күрсәтеп, мондый гариза һәм (яки) документларны эшләп бетерү өчен мөрәҗәгать итүчегә кире кайтара. Бу очракта айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү срогы биш эш көненә туктатып торыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган гариза һәм документлар, айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән) баш тарту турында) электрон рәвештәге карар проекты.»;

3.7.1 пунктта:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән) баш тарту турында) электрон рәвештәге карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән) баш тарту турында) электрон рәвештәге үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә юллый.»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен юлланган айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән) баш тарту турында) электрон рәвештәге карар.»;

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Үзәк бүлекчәсендәге белгечләрнең әлеге Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләрен үтәвен һәм башкаруын көндәлек тикшереп тору Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәүгә һәм башкаруга карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибен һәм рәвешләрен Үзәк директоры билгели.

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар әлеге Регламентка (белешмәлек) кушымтада китерелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору Министрлык аппараты бүлегенең һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) әлеге тикшереп торуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә.

4.3. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр

булган мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.4. Әлеге Регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Үзәкнең, Үзәк бүлекчәсенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк бүлекчәсе эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу мөмкинлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карау юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.2 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

Регламентка 1 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага
айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны
түләп бару буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү турында
ГАРИЗА[1]

______________________________________
(орган, оешма)

3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү (алга таба – айлык түләү) билгеләвегез турында үтенәм.

1. Мөрәҗәгать итүче турында мәгълүмат

ТӨП МӘГЪЛҮМАТЛАР

| | |
|---|---|
| Фамилия | _______________________________ |
| Исем | _______________________________ |
| Ата исеме (булган очракта) | _______________________________ |
| СНИЛС | _______________________________ |
| Шәхесне раслаучы документ турында белешмәләр (төре, бирелгән датасы, реквизитлары)[2] | _______________________________ |
| Туган датасы (көне, ае, елы) | _______________________________ |
| Гаилә хәле (беркайчан да өйләнмәгән (кияүгә чыкмаган), гаиләле, аерылган, тол ир (тол хатын)) | _______________________________ |
| Урнашкан урынының адресы[3] | _______________________________ |
| Аерылышу (өйләнешү) турындагы акт язуы реквизитлары[4] | _______________________________<br>(актны язу номеры) |

| | |
|---|---|
| | ______________________<br>(акт төзелгән дата) |
| | ______________________<br>(гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алган органның исеме) |
| Ир белән хатынның үлеме турындагы акт реквизитлары[5] | ______________________<br>(актны язу номеры) |
| | ______________________<br>(акт төзелгән дата) |
| | ______________________<br>(гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алган органның исеме) |
| | ______________________<br>(вафат булган затның Ф.И.А.) |
| | ______________________<br>(үлем датасы) |
| Эш урыны[6] | ______________________ |
| Эшкә алучының (салым агентының) ИНН[7] | ______________________ |
| Гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача кереме исәпләнгән чорда алынган алиментлар суммасы турында мәгълүмат | ______________________ |
| Гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү чорында караган эшкә яраксыз затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган датасы, СНИЛС[8] | ______________________ |

ӨСТӘМӘ МӘГЪЛҮМАТЛАР

| | |
|---|---|
| Гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорда | ӘЙЕ/ЮК<br>(кирәклесе астына сызарга); |

| | |
|---|---|
| ирektән мәхрүм итү урыннарында җәза үттем | ______________________<br>(гражданин җәза үтәгән Россия Федерациясе субъекты) |
| Гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү чорында һәм (яки) гариза бирү көнендә 6 ай яки аннан да күбрәк күләмде йөкле идем[9] | ӘЙЕ/ЮК<br>(кирәклесе астына сызарга); |
| Гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорда сак астында тоту рәвешендә чик кую чарасы кулланылган иде | ӘЙЕ/ЮК<br>(кирәклесе астына сызарга);<br>______________________<br>(гражданинга карата сак астында тоту рәвешендә чара кулланылган Россия Федерациясе субъекты) |
| Элемтә өчен мәгълүмат (телефон номеры, электрон почта адресы) | ______________________ |

2. Мөрәҗәгать итүченең хатыны турында мәгълүмат[10]

ТӨП МӘГЪЛҮМАТЛАР

| | |
|---|---|
| Фамилия | ______________________ |
| Исем | ______________________ |
| Ата исеме (булган очракта) | |
| СНИЛС | ______________________ |
| Гражданлыгы | ______________________ |
| Өйләнешү турында акт язуы реквизитлары | ______________________<br>(актны язу номеры)<br>______________________<br>(акт төзелгән дата)<br>______________________<br>(гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алган органның исеме) |
| Шәхесне раслаучы документ турында белешмәләр (төре, | ______________________ |

бирелгән датасы, реквизитлары)[2] ______________________________

Туган датасы (көне, ае, елы) ______________________________

Эш урыны[6] ______________________________

Эшкә алучының (салым агентының) ИНН[7] ______________________________

Гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача кереме исәпләнгән чорда алынган алиментлар суммасы турында мәгълүмат ______________________________

Гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү чорында караган эшкә яраксыз затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган датасы, СНИЛС[8] ______________________________

ӨСТӘМӘ МӘГЪЛҮМАТЛАР

Хәзерге вакытта яисә гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорда иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үттем

ӘЙЕ/ЮК
(кирәклесе астына сызарга);

______________________________
(гражданин җәза үтә торган Россия Федерациясе субъекты)

Ир белән хатынга карата сак астында тоту рәвешендә чик кую чарасы кулланылган яки гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорда мондый чара кулланылган

ӘЙЕ/ЮК
(кирәклесе астына сызарга);

______________________________
(гражданинга карата сак астында тоту рәвешендә чара кулланылган Россия Федерациясе субъекты)

Гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү чорында һәм (яки) гариза бирү көнендә 6 ай яки аннан да күбрәк күләмде йөкле идем[9]

ӘЙЕ/ЮК
(кирәклесе астына сызарга);

3. Мөрәҗәгать итүченең балалары турында мәгълүматлар[11]

ТӨП МӘГЪЛҮМАТЛАР

Фамилия ______________________________

| | |
|---|---|
| Исем | ____________________ |
| Ата исеме (булган очракта) | ____________________ |
| СНИЛС | ____________________ |
| Гражданлыгы | ____________________ |
| Туу турында акт язуы реквизитлары | ____________________<br>(актны язу номеры)<br>____________________<br>(акт төзелгән дата)<br>____________________<br>(гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алган органның исеме) |
| Шәхесне раслаучы документ турында белешмәләр (төре, бирелгән датасы, реквизитлары)[2] | ____________________ |
| Туган датасы (көне, ае, елы) | ____________________ |
| Мөрәҗәгать итүче баланың | ата-анасы/бүтән законлы вәкиле булып тора (кирәклесе астына сызарга); |

ӨСТӘМӘ МӘГЪЛҮМАТЛАР

| | |
|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яки көндезге уку формасы буенча югары уку йортында укый[12] | ӘЙЕ/ЮК<br>(кирәклесе астына сызарга); |
| Хәзерге вакытта яисә гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорда иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үттем[13] | ӘЙЕ/ЮК<br>(кирәклесе астына сызарга);<br>____________________<br>(гражданин җәза үтәгән Россия Федерациясе субъекты) |
| Балага карата сак астында тоту рәвешендә чик кую чарасы кулланылган яки гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорда мондый чара | ӘЙЕ/ЮК<br>(кирәклесе астына сызарга);<br>____________________<br>(гражданинга карата сак астында тоту |

| | |
|---|---|
| кулланылган[13] | рәвешендә чара кулланылган Россия Федерациясе субъекты) |

4. Гариза бирү көненә сезнең турында яки гаилә әгъзаларыгыз турында түбәндәге расламаларның берсе яки берничә дөрес булып торса, тиешле шакмакка тамга куегыз

□ Сезнең гаилә әгъзаларыгыз чакырылу буенча хәрби хезмәт үтә, хәрби һөнәри уку йортларында һәм югары белем бирүче хәрби уку йортларында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр булып тора.

□ Сезнең гаилә әгъзаларыгыз тулысынча дәүләт тәэминатында тора (опекага алынган мөрәҗәгать итүчедән һәм балалардан тыш).

□ Сезнең гаилә әгъзаларыгыз суд карары буенча мәҗбүри дәвалануда.

□ Сезгә яисә сезнең гаилә әгъзаларына Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән яисә сатып алу бәясе тулы күләмендә күчемле милек сатып алуга максатчан дәүләт социаль ярдәме кысаларында бирелгән акчалар хисабыннан түләнгән автотранспорт яки мототранспорт чарасы теркәлгән.

□ Сез яисә сезнең гаилә әгъзаларыгызның милегендә күпбалалы гаиләгә дәүләт социаль ярдәме кысаларында Россия Федерациясе субъектының яки муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән яисә аларны сатып алу бәясе күчемсез милек сатып алуга максатчан дәүләт ярдәме кысаларында бирелгән акчалар исәбеннән тулысынча түләнгән, «торак» билгеләнешендәге урыннар, «торак», «торак төзелмә», «торак йорт» билгеләнешендәге биналар, җир кишәрлекләре бар.

□ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары милегендә «Дәүләт һәм муниципаль милектә булган һәм Россия Федерациясенең Арктика зонасында һәм Россия Федерациясенең башка Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгыш территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре бар.

□ Сезнең милектә яисә сезнең гаилә әгъзалары милегендә гражданнар белән бер фатирда бергәләп яшәве мөмкин булмаган, катлаулы хроник авыру төрләренең Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган исемлегендә каралган хроник чирнең авыр формасыннан интегүче гаиә әгъзасы яши торган, «торак» билгеләнешендәге бүлмә (аның бер өлеше) бар;

□ Сезнең яки сезнең гаилә әгъзалары милегендә билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган, «торак» билгеләнешендәге урын (аның бер өлеше) бар.

□ Сезгә яки сезнең гаилә әгъзаларына арест салынган һәм (яки) эзләтүдә булган автотранспорт (мототранспорт), кечкенә көймә, үзйөрешле машина яки башка төр техника теркәлгән.

□ Сезнең гаиләгез күпбалалы статуска ия.

5. Гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнгән чорда сезнең турында яки сезнең гаилә әгъзалары турында түбәндәге расламаларның берсе яки берничәсе дөрес

булып торса, тиешле шакмакка билге куегыз[14]

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары Россия Федерациясеннән читтәге чыганаклардан алынган керемнәр алгансыз.

☐ Сез яки сезнең 23 яшьтән кечерәк гаилә әгъзалары гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары уку йортында көндезге форма буенча укыйсыз һәм стипендия алмыйбыз.

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары уку йортларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы затларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучы фән-педагогика кадрларына түләнә торган стипендияләр, Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалата түләүләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләре алгансыз.

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары чакырылу буенча хәрби хезмәт үткәнсез.

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары отставкага чыккан судьяларга гомер буе айлык түләү алгансыз.

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары дәүләт яки иҗтимагый бурычларны үтәгәндә дәүләт органы яки иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсацияләрне алгансыз.

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары 3 айдан артык вакыт дәвамында өзлексез дәвештә дәвалангансыз, шуның нәтиҗәсендә вакытлыча хезмәт эшчәнлеген башкара алмагансыз.

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган табышларны алып баргансыз.

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары хәрби хезмәттән, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендәге хезмәттән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле федераль дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнардагы хезмәттән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие алгансыз.

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары хәрби хезмәт, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле федераль дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнарда хезмәт итүче (хезмәт иткә) затлар ала торган пенсияне алгансыз.

6. Айлык түләүне гамәлгә ашыру ысулын билгеләү өчен, тиешле квадратка билге куегыз

☐ Кредит оешмасы аша:

кредит оешмасының исеме ______________________________

кредит оешмасының БИК ______________________________

мөрәҗәгать итүченең счет номеры ______________________________

☐ Почта бүлекчәсе аша:

алучының адресы ______________________________

почта бүлекчәсе номеры ______________________________

Дата «__» __________ 20__ ел. Мөрәҗәгать итүченең имзасы ______________________________

--------------------------------

[1] Айлык акчалата түләүне җиткерү ысулын үзгәртү максатында мөрәҗәгать иткән очракта, гариза кушымта нигезендәге форма буенча бирелә.

[2] Шәхесне таныклый торган документ сыйфатында Россия Федерациясе гражданины паспортын күрсәткән очракта, паспортның сериясе һәм номеры, бирелгән датасы, паспорт бирелгән бүлекчә коды, паспорт биргән органның исеме күрсәтелә.

Шәхесне таныклаучы документ сыйфатында туу турында таныклык күрсәтелгән очракта, туу турында акт язуы реквизитлары – актны язу номеры, актны язу датасы, гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алган органның исеме күрсәтелә.

[3] Яшәү урыны (тору) адресы күрсәтелә. Расланган яшәү (тору) урыны булмаган очракта, Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актларында каралган очракта, фактта яшәү адресы күрсәтелергә мөмкин.

[4] Мөрәҗәгать итүче «Гаилә хәле» графасында «аерылган» статусын күрсәткән булса, аерылышу турында акт язуы реквизитлары күрсәтелә. Мөрәҗәгать итүче «Гаилә хәле» графасында «тол» дип күрсәткән булса, өйләнешү турында акт язуы реквизитлары күрсәтелә.

[5] Мөрәҗәгать итүче «Гаилә хәле» графасында «тол» статусын күрсәткән очракта күрсәтелә.

[6] Мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның ире (хатыны) хәрби хезмәткәр, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, федераль куркынычсызлык хезмәте органнары, дәүләт сагы органнары, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия

Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләре, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре булып торган очракта күрсәтелә.

[7] Мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның ире (хатыны) хәрби хезмәткәр, Россия Федерациясе илкүләм гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре булган очракта күрсәтелә.

[8] Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) аның гаилә әгъзасы гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнгән чорда 18 яшькә кадәр инвалид баланы яисә балачактан ук I төркем инвалидны, яисә I төркем инвалидны яки дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә чит кеше тәрбиясенә мохтаҗ булган яки 80 яшенә җиткән карт кешене караган очракта күрсәтелә. Әлеге чорда хезмәткә сәләтсез булган берничә затны берьюлы караган очракта, хезмәткә сәләтсез булган һәр зат буенча белешмәләр күрсәтелә.

[9] Хатын-кыз затлар өчен тутырыла.

[10] Мөрәҗәгать итүче «Гаилә хәле» графасында «гаиләле» статусын күрсәткән очракта күрсәтелә.

[11] Гаилә составына керә торган һәр балага аерым тутырыла.

[12] Бала 18 яшьтән узган очракта тутырыла.

[13] Бала 14 яшьтән узган очракта тутырыла.

[14] Мөрәҗәгать итүче, гаиләнең җан башына уртача керемен төгәлләштерү максатында, түбәндәгеләрне раслый торган документларны тапшырырга хокуклы:

крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә генә оештырылган, эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәрне дә кертеп, гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорда эшкуарлык эшчәнлегеннән алынган керемнәр суммасын;

гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорда авторлык заказы һәм интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә махсус хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча керем суммасын;

салым салуның гадиләштерелгән системасын (әгәр гражданин салым салу объекты сыйфатында керемнәрне сайлаган булса), эшчәнлекнең аерым төрләре өчен кертелгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын, салым салуның патент системасын кулланып, гаиләнең җан башына уртача кереме исәпләнә торган чорга чыгымнары исәпкә алынган керем суммасын;

чыгымнарның максатчан характерына ия булган һәм эшкуарлыкка ярдәм итү кысаларында бирелә торган грантлар, субсидияләр һәм башка керемнәр.»;

Регламентка 3 нче кушымтада «(яңадан исәпләү)» сүзләрен төшереп калдырырга.